Сафин, Ф. "Авыл кешесе җиргә тартыла" / Ф. Сафин; [әңгәмәдәш] А. Гәрәев // Ирек мәйданы. – 2024. – №27 (11 июль). – Б. 8-9.





**Ир кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз, ди татар халык мәкале. Моның шулай икәнен яши-яши «й» тагын да ныграк аңлыйсың. Г.Тукай исемендәге премия лауреаты, язучы Факил САФИНның да һөнәрләрен күрсәң, исең-акылың китәр. Заманында ул механизатор да, мәдәният йорты директоры да була, әдәбият һәм тарих та укыта. Слесарь, бригадир, мастер һәм тагын әллә кемнәр булып эшләргә өлгерә. Ләкин ул Чаллыда язучы буларак киң таныла. 70 яшендә дә әле актив иҗат итә, шәһәрдә үткән барлык вакыйгаларда кайный. Факил абый ничек ял итә? Оныклары татарча беләме? Хатыны Ләйсирә апа белән ничә ел гомер итәләр? Бу хакта Факил Сафинның үзе белән сөйләшеп белдек.**

# "АВЫЛ КЕШЕСЕ ЖИРГӘ ТАРТЫЛА"

### "ҮҖӘТЛЕК БУЛДЫ. ӘММА КӨЧӘНЕП ЭШ БАШКАРМАДЫМ"

**— Факил абый, һич кенә дә сезгә *70* яшь дип уйламас идем. Сезнең турында егетләр кебек дип авыз тутырып әйтеп була. Яшь калуның сере нидә?**

— Авыл баласын кечкенәдән эшкә өйрәтеп үстерәләр бит. Хезмәт — тормыш бөтенлегенең нигезе, дигән нәрсә канга сеңгән. Беркайчан җинел эш эзләмәдем. Нинди Вазыйфага алынсам да, аны җиренә җиткереп башкарып чыгарга әзер булдым. Әткәй эш темасына сүз чыкса: "Җинел эш юк ул, акча — таш астында, тир түкмичә, бернәрсәгә дә ирешеп булмый". — ди иде. Шушыны үземә кулланма итеп алганмындыр, күрәсең.

Үҗәтлек булды, әмма көчәнеп эш башкармадым. Беркайчан да булдыра алмаган эшкә тотынмадым. Үз-үзенә ышанырга кирәк, әмма чаманны белү зарур. Кешегә салынмадым, иң авыр дип саналган өлешне үземә ала идем. Кул астында эшләгәннәрнең башларын юк-бар белән катырмадым, тәнкәләренә тимәдем. Эш урынында кешелекле атмосфера тудыру мөһим. Атналык җыелышта барысын да җентекләп сөйләшә идек, конкрет бурычлар билгеләнә, икенче атнада нәтиҗә ясала. Системага әйләнгән эш стилем шушы иде. Бүген дә шушы стиль саклана. Хәзерге көндә мин Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары – Язучыларның Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе (Нурлат районыннан алып Актанышка кадәр үннан артык район-шәһәрләр). Икенче Вазыйфам — Бөтендөнья татар конгрессының Яр Чаллы җирле оешмасы җитәкчесе. Монда җәмәгатьчелек белән эш итү сорала. Аның өстенә җәмәгать эшләрем бар. Актив иҗтимагый тормыш позициясе белән яшәү үземә дә тиешле дәрт-егәр бирәдер. Һәр Вазыйфаны җаваплы саныйм. Язучыларга артык басым ясамыйча, — ижатка этәргеч бирү кирәк. моны язучыларыбыз тоядыр дип уйлыйм. Тагын бер фактор бар — нәсел шулай безнең. Әткәйәнкәй тик торуны белмәделәр.





Әлбәттә, гаиләнең мине аңлавы бик кирәк. Ул яктан да Аллаһка шөкер. Балаларның үз тормышы, без үзебезчә тормыш арбасын тәгәрәтәбез. Күп йөрергә туры килә, хатыным Ләйсирә тормыш рәвешемне аңлый. Таң атканчы чыгып киткән бар, төнлә генә кайтып керәбез. Һәрвакыт озатып кала, каршы ала. Үзем 1972 елдан бирле рульдә. Язучыларны утыртам да очрашуларга барабыз, китап укучылар, әдәбият сөючеләр белән аралашу, төрле чаралар, юбилейлар үткәрү дә безнең эшкә керә.

**— Сезнең авылда каласыгыз килгән, әмма шәһәрдә төпләнгәнсез. Моңа нәрсә сәбәпче булды?**

— Авылда 30 яшькә кадәр укыттым, аннан мәктәп директоры итеп билгеләделәр. Әмма гел башка авылларда эшләргә туры килде. Үзебезнең мәктәптә урын ачылу белән, мәгариф бүлегенә гариза язам, тик авылга кайтармыйлар. Шактый еллардан соң әткәй ачыклык кертте. Мине авылга кайтартуны сорап, әткәй үзе райкомга барган. Райкомдагы түрә, әткәйнең гозерен — тыңлагач, ярып салган: "Малаең — директор, үзең мулла булып йөрерсенме? Муллалыгыңны ташла, шул чагында улыңны кайтарабыз". — дигән. Мәдрәсә белемен исәпкә алып, авыл картлары һәм авыл советы үгетләп, әткәй муллалык Вазыйфасын үтәүгә керешкән иде. Тагын бер мәртәбә гариза язгач, бәйләнү башланды. Яшь чак, сизми дә калдым, төшенкелеккә бирелү куркынычы алга килеп басты. Хатынымның нык холыклы булуы коткарды мине. Әткәй дә шул чагында кистереп әйтте: "Улым, авылга кайтам дип ашкынып йөрмә. Чаллыга кит, югалмассың. Туганнарың да шунда, бергәләп яшәрсез, безне дә ташламассыз". — диде. Чынлыкта ул мине алга таба тинтерәтеп йөрүләрдән саклап калды, иманына да тап төшермәде. Шул рәвешле мин, районда шактый танылган яшь директор, 1984 елда Чаллыга китеп урнаштым. Башта "КАМАЗ" заводында эшләдем, мастер, участок башлыгы булдым. СССР автомобиль сәнәгате буенча җиңү яуладым, заводның Мактау тактасына кертелдем. Үзгәртеп корулар башлангач, тулаем татар милләтенә хезмәт итү юлына күчтем. Хәзер дә шул юнәлештән туры атлыйм.

**— Заманында Казанга йөреп эшләгәнсез.**

— Язмыш төрле сынаулар китереп куя. Андый хәлләр дә булды. Яшьрәк чакта өйгә кайтып кергән, барлык ару-талулар онытыла иде. Гаилә җылысы дигән нәрсә дәрт-дәрман өсти. Гаилә учагын, билгеле, хатын-кыз сүндермичә саклый.

### ЛӘЙСИРӘ — АЛЛАҺЫМ БИРГӘН ИҢ ЗУР БҮЛӘК

**— Факил абый, Ләйсирә апа белән ничек таныштыгыз?**

— Ләйсирә белән 1976 елның 7 августында арыш басуында очраштык. Ул вакытта Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында читтән торып укый идем. Икенче курсны тәмамлап кайткач, үзем укыткан Мөслим районы Октябрь мәктәбеннән эшкә чакырып алдылар. Кырда арыш туземнәрен әйләндерергә кирәк икән. Ул елны явым-төшем мул булгандыр, күрәсең. Без — яшь укытучылар, һәркайсыбызның мотоциклы бар, тимер атка атланып, басуга чаптык. Җиң сызганып авыр туземнәрне әйләндерәм. Башкаларга күз дә салгалыйм — арада кызлар да күренә. Берсе бөтенләй таныш түгел, башкалардан калышмаска тырышып, баш күтәрми эшли бу. Җыйнак гәүдәле, кулына тоткан сәнәге үйнап кына тора, эш рәтен белүче авыл кызы. Күңел кыбырсып куйды. Монарчы бер кыз белән дә йөргәнем юк иде. Бераз ял итеп алганда, мәктәптә техничка булып эшләүче Галимә ападан сорашып белдем, әлеге кыз бухгалтер булып колхозга эшкә кайткан икән. Төшке ялга туктагач, кызлар узләре безнең янга килде. Егетләр барыбыз да башка авыллардан идек, кызлар исә шушы авылныкылар. Көлешеп-сөйләшеп торган арада, кызлар мотоциклар тирәсендә әйләнгәли башлады. Теге таныш булмаган кыз минем мотоцикл тирәсенә сырылган кебек. Тәвәккәлләп, кызга дәштем: "Апасы, бер әйләнеп килмәбезме әллә?" — дигән булдым. Кызның йөзе ачылып китте. "Бөркү, зыян итмәс иде". — ди, елмаеп. Сөйкемле инде, күз төшмәслек түгел. Шундый йомшак, авазларны ачык әйтеп, матур сөйләшкән кызны беренче күрүем иде. Менә шул мотоцикл белән җил куып килгән көннән бирле без бергә инде. Бер елдан өйләнештек, туй ясадык. Улыбыз Илнур, бераздан кызыбыз Гөлнар

туды. Ләйсирә — мина Аллаһым биргән иң зур бүләк.

**— Инде ярты гасыр үзган. Бүген ничек яшәп ятасыз? Балаларыгыз кайда эшли?**

— Тормыш корганга кырык сигезенче ел китте. Бездә элекке гореф-гадәткә нигезләнгән татар гаиләсе: ир — баш, хатын — муен. Улым Илнур — телләр белгече, кызым Гөлнар редакциядә эшли. Үз тормышларын үзләренчә көйләп яшиләр. Биш онык үсә. Иң мөһиме — балаларны хезмәткә өйрәтү, нәсел-нәсәпне, тамырларны белүләренә ирешү. Оныклар газиз туган телебезне белсен, татар телендә иркен аралашсын. Безнең өскә төшкән төп Вазыйфа шушы хәзер.

**— Татарча сөйләшәләрме соң?**

— Оныкларыбыз Кәрим, Камилә, Вәсилә, Мәдинә, Диләрәне тәрбияләүгә үз өлешебезне кертергә тырышабыз. Аларның татарча сөйләшүе — әби-бабай өчен зур куаныч. Бакчага баргач, берара русчага күчәләр. Шуннан соң аларда янәдән татарлык хисе "уяна". Менә шул чагында игътибарны арттырырга кирәк. Безнең балалар, оныклар да татарча газеталар, китаплар укый. Оныкларыбыз чын татар булып үсә. Бу — татар язучысы өчен аеруча зур бәхет. Мин моның өчен дә гаиләбез жылысын саклаучы Ләйсирәмә рәхмәтле. Димәк, ул балаларыбызга дөрес тәрбия биргән, рухый һәм милли кыйммәтләрне сеңдерергә тырышкан.

**— Факил абый, нинди ризыклар ашарга яратасыз? Дөрес туклануга игътибар бирәсезме? Үзегез нәрсәләр әзерлисез?**

— Ләйсирә нәрсә пешерсә, шуны рәхмәт әйтеп ашыйм. Хатыным аш булмәсендә кайнашкан ирләрне өнәми. Моны тиз анлап алдым да, ул чакырмыйча, кухняга чыкмаска тырышам. Аш кына пешерә беләм анысы, ач калмам кебек.

**— Бакчагыз бармы? Анда ниләр үстерәсез?**

— Авыл кешесе жиргә тартыла. Бакчабыз бар. Яшелчә, жиләк-жимеш үстерәбез. Тик мин төрле чараларга күп йөргәч, бакчага барырга вакыт кына житеп бетми. Бакчабыз шәһәрдән ерак, утыз чакрым ераклыкта урнашкан. Шунда ял да итәбез, эшлибез дә. Үзем дә, хатыным да шифаханә, ял, ижат йортлары дигән нәрсәләрне белмәдек.

Быел салкыннар харап итте. Алма, чия булырмы... Яшелчәләр булыр дип өмет итәбез. Кайнатма әзерли торган чор мәшәкатьле инде. Ләйсирә мәш килә. Быел бөтенләй коры калмас







өчен, сатып алып булса да кайнатма ясарбыз, дибез.

## "ӘСӘРЛӘРЕМНЕ ИКЕ-ӨЧ ЕЛ ЭЧЕНДӘ ЯЗЫП ТӨГӘЛЛИМ"

**— Жәен ижат итәргә вакытыгыз бармы? Хәзерге вакытта ижат итәсезме?**

— Ял, бәйрәм көннәрендә һәм аз-маз жәйге отпуск чорында язам. Ел саен бер повесть яки шигырьләр циклы "туа" торган иде. Быел ничек булыр. Алай илһам көтеп утырмыйм. Вакыт чыкса, каләмгә үреләм.

**— Факил абый, сез — "Биек тауның башларында", "Саташып аткан таң", "Шәүлә" романнары авторы. Бер роман язу өчен күпме вакыт китте? Аларны реаль тормыштан алып яздыгызмы? Бүген роман язу дәрәжә саналамы?**

— Бүген әдәби ижат дәрәжә санала дип әйтә алмыйм. Ул аерым бер затның миссиясе дип уйлыйм. Миссия ул — шушы урында, шушы вакытта, син (мин) генә башкарырга тиешле илаһи вазыйфа. Инде кырык ел шушы илаһи Вазыйфамны башкарам. Ниндидер дәрәжә турында уйламыйм. Совет чорында ижат кешесенә аерым бер каста итеп карадылар. Хәзер андый нәрсә юк. Роман язу—күңел таләбе ул. Язу эше — зур хезмәт. Берничек тә бәяләнми дип тә әйтә алмыйм. Ижатыма укучылар, житәкчеләр, әдәбият белгечләре дә игътибарлы булды.

Проза әсәрләрем — романнар, повестьлар, хикәяләр — барысы да реаль вакыйгаларга нигезләнгән. Шул ук вакытта автор күзаллаулары, фаразлары, хәтта уйдырмалары да бар. Әсәрләремне ике-өч ел эчендә язып төгәллим. "Саташып аткан таң" роман-трилогиясен язарга алты ел әзерләндем. Аны дүрт ел эчендә язып тәмамладым. Һәр зур әсәрне яхшы әзерлек белән яза башлау



кирәктер. Моны тәжрибәмнән чыгып әйтәм.

**— Чаллы ижат итү өчен жайлы шәһәрме?**

— Ижат өчен Чаллыдан да уңай шәһәр юк дип саныйм. Башка жирләрдә ныклап торып ижат белән булышмадым да. Казанда бер генә шигырь язылды. "Казан — шагыйрьләр шәһәре" дип атала ул. Ижат, ял йортларында язып азапланууны күз алдына китерә алмыйм. Чаллыда сулыш алу рәхәт, иркенлек, эчке хөрлек бар.

**— Үзегез кайсы авторларны укырга яратасыз?**

— Элекке язучыларны рәттән укый идек бит. Хәзер сайлап кына. Кайбер бик макталган авторларның язган әсәрләрен укый башлыйм да читкә алып куярга туры килә. Ашык-пошык, өстән генә язарга маһир каләм әһелләре ишәйде. Поэтик алымнар юк дәрәжәсендә. вакыйганы сөйләп чыгу, кешене юк-бар белән жәлеп итәргә омтылу һәм кабатланулар. Телевизордан күргәннәрен сипләштереп, әсәр дигән булып тәкъдим итәләр, иң арзаны — бер-берсен кабатлыйлар. Иң куркынычы — йомшак язмаларны әдәбиятыбыз казанышы дип тәкъдим итү барлыкка килде.

**— Дәүләт тарафыннан роман язган кешеләргә нинди ярдәм каралган?**

— Дәүләткә мин язсам ни дә, язмасам ни? Ә инде конкрет әйткәндә, урындагы житәкчеләр мина игътибарлы булды, юбилейларымны уткәрергә ярдәм иттеләр, һәрберсендә (50,60,70 яшьтә) зур кунаклар катнашты. Күңелем булды. Ниндидер матди ярдәм турында уйлап та караганым булмады. Ижатымны, хезмәтемне бәяләделәр, зур дәрәжәләргә ирештем. Аллаһка шөкер итәм. Мина хәер-хаһлы булган һәммә кешегә рәхмәт белдерәм. Гомерем бәрәкәтле үтте, хезмәтсез бер генә көнем дә узмады.

**— Ижат иткән кайсы чорыгыз кадерле?**

—Гомеремнең һәр мизгеле кадерле. Аллаһка шөкер, трай тибеп, юкны бушка аударып, буш куык булып йөрмәдем. Кулымнан килгәнчә башкаларга ярдәм иттем, хәзер дә мөмкинлек табып, мохтажларга, аеруча язучыларыбызга ярдәм итү өчен жай табарга тырышам. Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла да мондый гозерләремә игътибар итми калмый. Башкаларны кайгырту каныма сеңгән, рәхмәт әйтсеннәр дип эшләмим, жан таләбем шушы.

**— Яшәргә көч, энергияне каян аласыз?**

— Каян алганымны белмим. Аллаһ шулай яраткан инде, гел хезмәттә, хәрәкәттә — яшәү рәвешем шул. Хәрәкәттә — бәрәкәт, диләр, хак сүздер.

**— Бу тормышта чынга ашмаган планнарыгыз, хыялларыгыз бармы?**

— Буш хыяллар белән яшәргә күнекмәгән мин. Ниндидер эшкә ният кылам икән, ул, әлбәттә, реаль була, аны эшләп чыкмыйча, туктамыйм. Армиядә (взвод командиры урынбасары идем) мине офицерлар "маленький танк" дип йөртә иде. "КАМАЗ"да кушаматым "укытучы" булды. Эшчеләр туры сүзле, хәрәкәтчән, төгәл булганым, аларның мәнфәгатен кайгыртканым өчен яратты. Гомер буе үз-үзем белән килешеп яшәдем. Холкым үзгәрмәде, шөкер, әле дә шулай дәвам итә.

**Арыслан ГӘРӘЕВ.**